# ЧИШМӘ БАШЫ

*СЕҖЕ ТӨП ГОМУМИ  БЕЛЕМ МӘКТӘБЕ*

*март, 2025*

| БАШ БИТ | ЯҢАЛЫКЛАР | ТӨРЛЕЛӘР | БӨЕК ҖИҢҮГӘ-80 ЕЛ |
|---|---|---|---|
| 8 МАРТ ХАТЫН-КЫЗЛАР КӨНЕ -  1 БИТ | МӘКТӘП ТОРМЫШЫ- 2 БИТ | БАШВАТКЫЧЛАР – 3 БИТ | ХАТИРӘЛӘР- 4 БИТ |

# 8 МАРТ ХАТЫН – КЫЗЛАР КӨНЕ

## Җәннәт – әниләрнең аяк астында




Һәркемнең тормышында иң изге кеше ул – әни. Чын күңелдән безне яратучы бердәнбер кеше дә – әни. Ялгышларыбызны, хаталарыбызны һәрдаим гафу итүче, кичерә белүче иң олы йөрәкле кеше дә – әни. Ничә яшебезгә җитсәк тә, безне сабый бала кебек кайгыртып, безнең өчен ут йотып яшәүче дә – әни. Дөньяга аваз салуга ук ул безне җил-яңгырдан саклап үстерә, олы тормыш юлына әзерли, акыллы киңәшләре белән ярдәм итеп тора.


8 март хатын – кызларны олылау көне, матурлык бәйрәме. Әлеге бәйрәм башка бәйрәмнәрдән яктырак та, җылырак та, мөлаемрак та шикелле. Шуңа күрә дә менә бу бәйрәмне кешелек дөньясы 1913 нче елдан ук бәйрәм итеп килә.

Сезне бөтен җир йөзен бизәгән яз бәйрәме – Халыкара хатын – кызлар көне белән тәбриклибез. Сезгә озын гомер, елмаеп балкыган кояш матурлыгы, укуыгызда зурдан –зур уңышлар телибез.

---





Укучылар әниләренә үз куллары белән барлык күңел җылыларын биреп бүләкләр ясадылар.
Нәни кулларым белән әниемә диеп кенә
Әзерләдем бүләгемне
Бик зур көч куеп менә!
Бәйрәм белән, кадерле әниләребез!

“Туган телем сагында” акциясе кысаларында 5-9 класслар арасында

“Иң кадерлем-әнием!” темасына иншалар бәйгесе үткәрелде. Укучыларның язмалары аша шуны әйтергә була: әни – җирдә иң газиз, якын кеше! Ул сине тудырган, көйләп бишектә тирбәткән, синең беренче елмаюыңны, тәпи атлап китүеңне күреп шатланган, туган телен, халык моңнарын яратырга өйрәткән.

Бүген мәктәбебездә 8 Март - Халыкара хатын-кызлар көне уңаеннан бәйрәм чарасы булып узды. Бәйрәм бик күңелле үтте. Балалар әниләре белән бергә бик күп төрле кызыклы ярышларда катнаштылар.



**Волонтёрлар махсус хәрби операциядә катнашкан егетләребезнең әниләрен бәйрәм белән котладылар.**



**“Бәйрәм белән котла” акциясе кысаларында укучылар Сеже авылында яшәүче тыл ветераны Фәния апаны( сулда) һәм хезмәт ветераны Җиһания апаларны бәйрәм белән котладылар**.



**8 Март бәйрәме белән котлап волонтёрларыбыз Ташкич авылында яшәүче тыл ветераны Рәйсә апа янында булдылар**



**Күп еллар буе мәктәбебездә укучыларга тарих һәм җәмгыять белеме фәннәреннән белем биргән ветеран укытучыбыз - Нурания Йосыф кызы**

# *“НӘҮРҮЗ МӨБӘРӘКБАД!”*



21 март көнне мәктәптә "Нәүрүз" бәйрәме булып узды. Укучылар башта тәмле карга боткасы белән сыйландылар, аннары аркан тартыш, чүлмәк вату, урындык тирәли бию , кашык кабып йөгерү, таяк тартыш уеннары уйнадылар. Балалар уеннарда бик теләп катнаштылар. Нәүрүз – төрки һәм фарсы телле халыкларның бик борынгыдан килгән бәйрәме.

Ул 21 мартта көн белән төн тигезләшкән көнгә туры килә.

## Укучыларыбыз район күләм ярышларда актив катнашалар





Канатлы дусларыбызга сыерчык оялары ясау – мәктәбебездәге матур гадәтләрнең берсе. Быел да мәктәп күләмендә “Яраткан кошларыбызга – оя” конкурсы булды. Бу изге эштә катнашкан укучыларыбызга, әти-әниләргә рәхмәтебезне җиткерәбез.“Җиңүчеләрне Кошлар көнендә игълан итәчәкбез”, - ди тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Гөлнара Фирдусовна.

Укучылар, бик тырышып, әти-әниләре ярдәмендә оялар ясаган.

Төрле-төрле оялар тиздән хуҗаларын да каршы алыр.

## Шахмат-акыллылар уены




КАНИКУЛЛАР КЫЗЫКЛЫ ҺӘМ ФАЙДАЛЫ ҮТӘ








## *ЯЛ ИТЕП АЛЫЙК*









# Бөек Ватан сугышы минем гаиләмдә.




Хәтерләүдән курыкма син!
Үткәнеңне онытма син!
Бел син ерак бабайларның
ничек итеп көн иткәнен,
ни иккәнен, ни чиккәнен,
нинди уйлар, нинди моңнар
безгә калдырып киткәнен.
Исеңдә тот, аларның син
сугышларда кан түккәнен,
Туган җирнең ирекне өчен,
зинданнарда интеккәнен...

Равил Файзуллин.

Язлар җитә, язлар... Көннәр шактый салкын торуга да карамастан, тышта яз исе, яшәү, тереклек исе аңкый. 80 ел элек тә җиргә шундый язлар килгәндер. Юк, ул язлар тулы бер кешелекнең өметен, ышанычын аклаган язлар булган бит. Яз һәркемдә яңа хыяллар, өмет, ышаныч уята. Ул авыр елларда да шушы өмет, ышаныч, бер-берсенә терәк була белү авырлыкларны җиңеп чыгарга ярдәм иткәндер, мөгаен. Илебезгә шактый кыйммәткә төшкән бу җиңү шатлыгын үз күзләре белән күреп, безгә тынычлык бүләк итүчеләрнең саны да бүген авылларда санаулы булып тора. Яшисе килү теләге, тормышны, туган җирне ярату барысыннан да көчлерәк булган күрәсең. Нәкъ шушы чор кешеләре үз язмышына төшкән сынауларны сыкранмый, намусына тап төшерми үтә белгән буын.

Мин, Зарипов Салават, дәү әтинең әтисе турында язарга булдым. Ул 1926 елның 1 декабрендә дөньяга килә. Бабам Низамиев Шәмсетдин Низами улына сугыш башланганда бары тик 15 яшь була. 17 яшендә немецлар белән сугышканда, снаряд эләгеп, бот төбеннән сул аягын өздерә. Аягы төзәлгәнче ул госпитальдә дәвалана.1944 елда ул “Кызыл Йолдыз” ордены белән бүләкләнә. Бабам кебек егетләр, яшь булуларына карамастан, җиңү яулап, безгә тыныч тормыш, аяз күк йөзе бүләк иткәннәр. Тормышлары әле башланырга да өлгермәгән, уй-хыялларга бай егетләрнең күбесе яу кырларыннан кире әйләнеп кайтмаган.

Бабам сугыштан исән-имин кайта. Күрәсең, бәхете белән туган ул. Озын, авыр була сугыш еллары. Бабайны авылга кайтаралар һәм аны бригадир итеп куялар. Колхоздан мотоцикл бирәләр, ул кешеләргә эшкә әйтә,басудагы игеннәрне эшкәрттерә. Колхозны алга алып барырга тырыша сугыш булуга карамастан. Сугыш тәмамлаганнан соң бабайга аягына протезлар ясатып кайтаралар. Бер аяклы булуына карамастан, ул әбигә өйләнә.Әби колхозда тракторда эшләүче кыз булып чыга. Алар бик тырыш булалар,йорт салып чыгалар. Бер малай бер кыз үстерәләр. Бабай белән әбинең балалары дөньядан бик иртә китәләр. Икесенә дә 56 яшь кенә була. 2009 нчы елны, ике балаларын да югалтуны күтәрә алмыйча, икесе дә дөнья белән хушлаштылар.

Бабамны, кызганычка каршы, бер генә тапкыр күреп калдым. Мин аны сагынам һәм аның белән горурланам .

Зарипов Салават, 6 нчы сыйныф укучысы

**Редакция һәм нәшриятның адресы:**
**422027, Татарстан Республикасы,**
**Арча районы, Сеҗе авылы,**
**Мәктәп урамы, 21 нче йорт**
**Тел: E- mail: Ssiz.Ars@tatar.ru**
**Газетаны гамәлгә куючы:китапханәче-**
**Закирова Солтания Рәсим кызы**